| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>ул.Советская дом 55А, село Лашманка, 423110 | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**<br>Советлар урамы,55Айорт, Лашман авылы, 423110 |
|---|---|---|

тел./факс +7(84396) 2-92-35 email: Lash.Cmn2@tatar.ru


№ 92 18 сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге №26 «Лашман авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Лашман авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге № 286-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Лашман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге № 26 «Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» карарының 1 кушымтасының 16 пунктының 2 абзацын (2021 елның 16 июнендәге № 25, 2022 елның 18 маендагы № 55 үзгәрешләре белән) яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль вазыйфаны биләүче затның үз чыгымнары турында белешмә бирмәве, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирүе, яисә үз чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирүе яки хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында белешмәләр бирмәү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүмат тапшыру, яки хатынының (иренең) һәм балигъ

булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган мәгълүмат бирү, әгәр мондый мәгълүматны тапшыру мәҗбүри булса, гамәлдәге закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә аны белгән вазифасыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Р.Г.Фәттахов